# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 102 2022 ел, 16 февраль

Аксубай муниципаль районы Советының
«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставы турында»
17.10.2019 ел, № 216 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законга үзгәрешләр кертү белән бәйле, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставы нигезендә, Аксубай районы прокуратурасы күрсәтмәсен карап, Аксубай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына беренче укылышта тәкъдим ителгән үзгәрешләр проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә.

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проекты;
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү һәм гражданнарның фикер алышуда катнашуы проектына карата 2 нче кушымта нигезендә гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе;
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча 3 нче кушымта нигезендә ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе.

3. Әлеге карарның ачык тыңлауларын 21.03.2022 ел, 10.00 сәгатьтә район Советының утырышлар залында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: ТР, Аксубай муниципаль районы, Аксубай штп, Ленин ур., 8.

4. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

1.Заһидуллин И. М., төркем җитәкчесе

2. Телешева И. А., төркем әгъзасы

3. Шакиров И. Р., төркем әгъзасы

4. Емельянов А. А., төркем әгъзасы

5. Тарасова С. А., төркем әгъзасы

5. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проектына карата тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча җибәрергә: 423060, ТР, Аксубай муниципаль районы, Аксубай штп, Ленин ур., 8 йорт, 3 нче каб.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставы проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе К.К. Гыйлманов

Аксубай муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

43 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 19 пунктча өстәргә:

«19) муниципаль янгын сагы булдыру.».

7 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 19 пунктча өстәргә:

«19) муниципаль янгын сагы булдыру.».

6 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9_1 пунктча өстәргә:

«9_1) муниципаль районнар чикләрендә шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;»;

7 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 19 пунктча өстәргә:

«19) муниципаль янгын сагы булдыру.».

89 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Муниципаль берәмлек Уставы, муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт аларның дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми рәвештә бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә) тиеш һәм алар рәсми рәвештә басылып чыкканнан (халыкка игълан итәргәннән) соң үз көченә керә. Муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль берәмлекнең теркәлгән уставын, муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан муниципаль берәмлек Уставы турында белешмәләр кертү турында хәбәрнамәләр кергән көннән алып җиде көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә) бурычлы, муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый актта «Муниципаль берәмлекләр Уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 21.07.2005 ел, № 97-ФЗ Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында.»

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ҺӘМ ГРАЖДАННАРНЫҢ АНЫҢ ФИКЕР АЛЫШУДА КАТНАШУЫ ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 423060, ТР, Аксубай муниципаль районы, шәһәр тибындагы Аксубай штп, Ленин ур., 8, 3 нче каб., язма рәвештә.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatar.ru рәсми сайтында халыкка иглан ителгән көннән башлап кабул ителә:

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423060, ТР, Аксубай муниципаль районы, Аксубай штп, Ленин ур., 8 йорт, 3 нче каб., шәхсән яки почта аша («Уставка үзгәрешләр кертү турында фикер алышу» конверттагы билге белән).

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСТАВЫ ПРОЕКТЫ БУЕНЧА АЧЫК ТЫҢЛАУЛАР ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты турында» ачык тыңлаулары (алга таба- ачык тыңлаулары) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставының 17 нче статьясы нигезендә уздырыла.

2.Ачык тыңлауларда катнашучылар үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советына язма гариза биргән район халкы катнаша.

3.Ачык тыңлауларда халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка районның барлык кызыксынган кешеләре катнаша ала.

4.Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 30 минут алдан башлана.

5.Халык тыңлауларында рәислек итүче булып Районы башлыгы тора. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

6.Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, рекомендацияләрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча секретариат җитәкчесе һәм секретариатның ике әгъзасы составында ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.

7. Төп доклад белән Аксубай муниципаль районы Советы депутаты чыгыш ясый.

8. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашучылар гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

9. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

10. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга, чыгыш тәмамланганнан соң, рәис рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыгылырга, аларны өзәргә һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

12. Ачык тыңлаулар үткәргәндә тәртипне үтәү мәҗбүри шарт булып тора.

13. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

14. Чыгышлар тәмамлангач, рәислек итүче ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, рекомендацияләрне ачыклау өчен ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

15. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә кушыла. Ачык тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм Аксубай муниципаль районы Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

16. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

17. Ачык тыңлауларын уздыруны оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Аксубай муниципаль районы Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.